ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«08» декабрь 2020 ел № 403

**2021 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында**

«Мәктәптә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең хакы нормативлары турында» 2010 елның 06 декабрендәге 1013 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең модельле норматив хокукый акты проекты турында» 2020 елның 28 октябрендәге 01/1911 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

- 2021 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләре нормативлары;

- гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру буенча әлеге карарның 1 пунктында расланган укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерже муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.12.2020 № 403
карары белән расланган

2021 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләре нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер километр узган юлына ставка, сум |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| ГАЗ «Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 151544 | 35,91 |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
08.12.2020 № 403
карары белән расланган

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын ташуны оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.
1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең, автотранспорт чаралары санының һәм хисап чорына автотранспорт чараларының фактта йөрүенең нормативы нигезендә исәпләнә.
1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакы нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.
1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча, автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасынын факттагы узган юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

кайда:
$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;
$n_{f\,m}$ - m моделе автотранспорт чараларының фактик узган юлы, километр;
$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны ташуны оештыру бәясенең нормасы бер километрга, сум;

$NF_{as\ m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән балаларны ташуны оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына нормасы ставкасы, сум;

$M_m$ - m моделенең автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар моделе саны.